РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.18 г. Бугульма № 264

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрен Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы торак микрорайоннары территорияләренә беркетү турында**

29.12.2012 №273 –ФЗ «Россия Федерациясенең мәгариф турында» Федераль законына таянып, 08.04.2014 елның №293 РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча кабул итү тәртибен раслау турында», мәктәпкәчә яшьтәге балаларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру, аларны мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләре арасында тигез итеп бүлүне гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук файдалануга тапшырылган яңа торак объектларын исәпкә алып, Башкарма комитет Карар бирә:

1. Бөгелмә шәһәре һәм Бөгелмә районының торак микрорайоннарының чикләрен билгеләү, ТР Бөгелмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрен әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә ТР Бөгелмә муниципаль районының торак микрорайоннары территорияләренә беркетергә.

2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә беркетелгән торак микрорайоннарында яшәүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларга, социаль-педагогик мониторинг, исәпкә алу буенча чаралар үткәрергә.

3. ТР Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары- мәгариф идарәсе Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты башлыгына (КульбедаВ.В.) торак микрорайоннарда яшәүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларны социаль-педагогик исәпкә алу, мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыру буенча мониторинг үткәрергә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты башлыгына Кульбеда В.В. йөкләргә.

**Бөгелмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Р.Галиуллин**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ